КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1735

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә метрополитенда пассажирларны йөртү һәм билгеләнгән нормалардан тыш кул йөге ташу буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифлар билгеләү турында» 2019 ел, 28 декабрь, 1227 нче карары кушымтасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә метрополитенда пассажирларны йөртү һәм билгеләнгән нормалардан тыш кул йөге ташу буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифлар билгеләү турында» 2019 ел, 28 декабрь, 1227 нче карарының (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 2 август, 670 нче; 2022 ел, 18 май, 462 нче; 2023 ел, 9 гыйнвар, 1 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымтасына, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 декабрь, 1227 нче
карарына кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 29 декабрь, 1735 нче
карары редакциясендә)

## Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә метрополитенда пассажирларны йөртү һәм билгеләнгән нормалардан тыш кул йөге ташу буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифлар

| Пассажирлар йөртү буенча хезмәт күрсәтүләргә бер тапкыр транспортта йөрүгә тарифлар, сум | | | | | Билгеләнгән нормалардан тыш кул йөге ташу буенча хезмәт күрсәтүләргә тариф[5], сум |
|---|---|---|---|---|---|
| бер тапкыр бирелә торган билет сатып алганда[1] | | транспортта йөрү өчен банк карталары ярдәмендә түләгәндә[2] | транспортта йөрү өчен озак файдаланудагы билетлар белән түләгәндә (транспорт картасы) | | |
| акча белән исәп-хисап өчен | акчасыз исәп-хисап өчен | | 1 тапкыр транспортта йөрүгә[3] | 100 һәм аннан күбрәк транспортта йөрүгә[4] | |
| 42 | 38 | 38 | 38 | 28 | 38 |

[1] Метрополитен кассаларында жетон (билет) сатып алганда.
[2] Транспорт кушымтасыннан башка банк карталары белән транспортта йөрү өчен түләгәндә.
[3] Билгеләнгән сумма чикләрендә транспортта йөрү хокукын бирә торган озак вакытлы файдаланудагы билетлар һәм транспорт кушымтасы булган банк карталары белән транспортта йөрү өчен түләгәндә.
[4] Күрсәтелгән вакыт дәвамында транспортта билгеләнгән тапкыр йөрүгә хокук бирә торган озак файдаланудагы билетлар белән транспортта йөрү өчен түләгәндә.
[5] Билгеләнгән нормалардан тыш кул йөге ташу бәясе өчен түләү транспортта йөрү бәясе өчен түләүдән аерым башкарыла.

_______________________